Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл җирлегенең
Габдрахман торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы
КАРАРЫ

22 ноябрь 2021 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2021 елның 20 ноябре 08 сәгать 00 минутта, 2021 елның 20 ноябре 10 сәгать 00 минутта, 2021 елның 20 ноябре 12 сәгать 00 минутта, 2021 елның 20 ноябре 14 сәгать 00 минутта, узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә: “Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Габдрахман авыл җирлегенең Габдрахман авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: скважина бораулау, су белән тәэмин итү системасын норматив халәткә китерү, проект-смета документларын эшләү өчен түләү, күрсәтелгән эш төрләренә техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү?” соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 1129 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 691 кеше, бу 61,2 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 691-е «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде;

гражданнар җыенында катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл җирлегенең Габдрахман торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл җирлегенең Габдрахман авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән үзара салым средстволарын 2022 елда 400 сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә: скважина бораулау, су белән тәэмин итү системасын норматив халәткә китерү, проект-смета документларын эшләү өчен түләү, күрсәтелгән эш төрләренә техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү.

4. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетысында бастырырга, Габдрахман авылы, Совет урамы 77 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Р.Ш.Мотаһиров

Р.05-11256/12
«АБДРАХМАНОВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ СОВЕТ»
ИНН 1607002265
КПП 164401001